Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.10.2019 Менделеевск ш. № 598

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр
Декадасын үткәрү турында

Мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында, Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясенең 2006 елның 13 декабрендәге 61\106 номерлы карары белән кабул ителгән инвалидларның хокуклары турындагы Конвенцияне тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Районда 2019 елның 2 декабреннән 12 декабренә кадәр сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр ункөнлеген уздырырга.

2. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр Декадасына багышланган чараларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын төзергә һәм расларга (1 нче кушымта).

3. Менделеевск муниципаль районында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр декадасын үткәрү буенча чаралар планын (2 нче кушымта), чаралар үткәрүгә сметасын расларга (3 нче кушымта).

4. Барлык милек формасындагы авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә үз предприятиеләренең мөмкинлекләре чикләнгән хезмәткәрләрен коллективларда тәбрикләргә, бүләкләр тапшырырга, районда үткәрелә торган хәйрия чараларында актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Менделеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Григорьев М.В.) смета буенча чаралар үткәрүгә акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә (3 нче кушымта)

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Сәфәргалинга йөкләргә.

Җитәкче Хамматов А.З.

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

| | |
|---|---|
| Финанс-бюджет палатасы рәисе | Григорьев М.В. |
| Җитәкче урынбасары | Сәфәргалин А.Н. |
| Юридик бүлек башлыгы | Царева Е.С. |